| СОВЕТ БОЛЬШЕАКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР АКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

с. Большая Акса

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02 апрель 2026 ел № 7/1

Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге кайбер муниципаль актларны гамәлдән чыккан дип тану турында

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы "Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларны гамәлдән чыгару турында"гы Указының 4 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

1) 2017 елның 07 августындагы 34/1 "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итү тәртибен раслау турында";

2) 2021 елның 29 июнендәге 10/1 номерлы "Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында мәгълүмат бирү һәм керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы кайбер карарларга үзгәрешләр кертү турында";

3) 2015 елның 27 мартындагы 60/3 номерлы "ТР Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук ТР Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәне раслау турында";

4) 2018 елның 26 октябрендәге 60/2 номерлы "ТР Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына

дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук ТР Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында";

5) 2022 елның 07 июнендәге 19/2 номерлы "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында";

6) 2023 елның 29 сентябрендәге 38/1 номерлы "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында".

2. Бу карарны Татарстан Республикасының Хокукый Мәгълүматның Рәсми Порталында бастырып чыгарырга.
3. Бу карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Зур Аксу авыл җирлеге башлыгы: В.В. Митрошкин